**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы**
**муниципаль беремлеге**
**423072 Иске Тимошка**
**Авылы Ленина урамы, 27**
**тел. 884344 4-53-40**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Аксубаевский муниципальный**
**район муниципальное образование**
**423072 с.Старое Тимошкино**
**улица Ленина, 27**
**тел. 884344 4-53-40**

СОВЕТ СТАРОТИМОШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

КАРАР

№ 1 15.11. 2025 ел

«Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлеге
Иске Тимошкино торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү
һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында"

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы«Иске Тимошкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә

КАРАР:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлеге Иске Тимошкино торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 24 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Иске Тимошкино авылы Ленин урамы, 27 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында уздыру билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлеге Иске Тимошкино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Федерациясенең махсус операцияләрдә катнашучы хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

**1. Җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кышкы карап тоту, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу)

**2. Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру,җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән**

**инвалидлар файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

- Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (җәйге вакытта территорияне чабу - ягулык-майлау материаллары, триммер өчен запас частьләр сатып алу, эшләр өчен килешү буенча түләү);

**3.Торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү**

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, янгын сүндерү машинасын йөртүчеләрнең хезмәт хакы);

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны"Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында " түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru , авыл җирлегендә яшәүчеләрнең күпләп җыела торган урыннарына, стендларга һәм такталарга белдерүләр элү юлы белән халыкка игълан итәргә, шулай ук Аксубай муниципаль районы «Интернет»мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

4.Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Аксубай муниципаль районы
Иске Тимошкино авыл җирлеге башлыгы Н.М.Сандимиров